**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Положение об организации и ведении гражданской обороны в Республике Татарстан**

В связи с изменениями в федеральном законодательстве в области гражданской обороны **постановляю:**

1. Внести в Положение об организации и ведении гражданской обороны в Республике Татарстан, утвержденное Указом Президента Республики Татарстан от 22 ноября 2008 года № УП-598 «Об утверждении Положения об организации и ведении гражданской обороны в Республике Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 17 октября 2014 года № УП-995, от 19 января 2016 года № УП-18, от 4 июня 2016 года № УП-502, от 27 января 2020 года № УП-27, от 23 апреля 2022 года № УП-297, указами Раиса Республики Татарстан от 24 марта 2023 года № 187 и от 26 июля 2024 года № 563), следующие изменения:

а) раздел 2 признать утратившим силу;

б) в абзаце первом пункта 3.2 слова «при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера» заменить словами «в период мобилизации, в период действия военного положения, в военное время»;

в) в пункте 3.3:

в абзаце первом слова «материальных и культурных ценностей в безопасные районы» заменить словами «защите материальных и культурных ценностей»;

абзац второй дополнить словами «населения, защиты материальных и культурных ценностей»;

г) в абзаце четвертом пункта 3.4 слова «в военное время» исключить;

д) в пункте 3.6:

в абзаце первом слова «возникновения опасности для населения при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера» заменить словами «опасностей, возникающих в период мобилизации, в период действия военного положения, в военное время»;

в абзаце втором слова «обороны и» заменить словами «обороны, оснащение и подготовка необходимых сил»;

е) в пункте 3.7:

в абзаце первом слова «при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера» заменить словами «в результате опасностей, возникающих в период мобилизации, в период действия военного положения, в военное время»;

абзац четвертый признать утратившим силу;

в абзаце шестом слова «при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов» заменить словами «в результате опасностей, возникающих в период мобилизации, в период действия военного положения, в военное время»;

в абзаце девятом слова «домах отдыха, пансионатах и других оздоровительных учреждениях, временных жилищах (сборных домах, палатках, землянках и т.п.), а также осуществление подселения населения на площадь сохранившегося жилого фонда» заменить словами «пунктах временного размещения и питания»;

ж) в пункте 3.8:

в абзаце первом слова «возникшими при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов» заменить словами «произошедшими в результате опасностей, возникающих в период мобилизации, в период действия военного положения, в военное время»;

в абзаце третьем слова «в военное время» исключить;

в абзаце четвертом слова «, в военное время» исключить;

з) в абзаце первом пункта 3.11 слова «при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера» заменить словами «в результате опасностей, возникающих в период мобилизации, в период действия военного положения, в военное время»;

и) в пункте 3.14:

в абзаце первом слова «военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера» заменить словами «опасностях, возникающих в период мобилизации, в период действия военного положения, в военное время»;

в абзаце втором слова «в мирное и военное время» исключить;

в абзаце пятом слова «в мирное и военное время» исключить;

к) в пункте 4.8:

в абзаце втором слова «на территории Республики Татарстан» исключить;

абзац третий изложить в следующей редакции:

«территориальный орган федерального органа исполнительной власти, уполномоченного на решение задач в области гражданской обороны;»;

л) в пункте 4.13:

абзац первый дополнить словами «из числа своих работников в целях участия в обеспечении выполнения мероприятий по гражданской обороне и проведения не связанных с угрозой жизни и здоровью людей неотложных работ при ликвидации чрезвычайных ситуаций»;

в абзаце третьем слова «создают и поддерживают в состоянии готовности локальные системы оповещения» заменить словами «создают, реконструируют и поддерживают в состоянии постоянной готовности к использованию локальные системы оповещения населения»;

м) абзац первый пункта 4.17 изложить в следующей редакции:

«4.17. Для осуществления управления гражданской обороной органы исполнительной власти Республики Татарстан, органы местного самоуправления и организации в соответствии с полномочиями в области гражданской обороны создают, реконструируют и поддерживают в состоянии постоянной готовности к использованию технические системы управления гражданской обороны, системы оповещения населения.»;

н) пункт 4.19 изложить в следующей редакции:

«4.19. Координация деятельности территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов местного самоуправления и организаций при проведении указанными органами и организациями мероприятий по гражданской обороне осуществляется Комиссией по предупреждению и ликвидации чрезвычайных ситуаций и обеспечению пожарной безопасности Республики Татарстан, созданной в соответствии с Федеральным законом от 21 декабря 1994 года № 68-ФЗ «О защите населения и территорий от чрезвычайных ситуаций природного и техногенного характера».

Обеспечение координации деятельности органов управления гражданской обороной, управления силами и средствами гражданской обороны, организации информационного взаимодействия территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления и организаций при решении задач в области гражданской обороны, а также при осуществлении мер информационной поддержки принятия решений в области гражданской обороны в соответствии с федеральным законодательством осуществляет центр управления в кризисных ситуациях Главного управления МЧС России по Республике Татарстан.»;

о) пункт 5.1 изложить в следующей редакции:

«5.1. Подготовка к ведению гражданской обороны на территории Республики Татарстан заключается в заблаговременном выполнении мероприятий по подготовке к защите населения, материальных и культурных ценностей от опасностей, возникающих в период мобилизации, в период действия военного положения, в военное время.»;

п) в пункте 5.2 слова «при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при возникновении чрезвычайных ситуаций природного и техногенного характера» заменить словами «в период мобилизации, в период действия военного положения, в военное время»;

р) в пункте 5.3 слова «и ликвидации чрезвычайных ситуаций природного и техногенного характера в военное время» исключить.

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
19 июня 2026 года
№ 491

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында граждан оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Граждан оборонасы өлкәсендә федераль законнарга үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы, 2016 елның 19 гыйнварындагы ПУ-18 номерлы, 2016 елның 4 июнендәге ПУ-502 номерлы, 2020 елның 27 гыйнварындагы ПУ-27 номерлы, 2022 елның 23 апрелендәге ПУ-297 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 24 мартындагы 187 номерлы һәм 2024 елның 26 июлендәге 563 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында граждан оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 бүлекне үз көчен югалткан дип танырга;

б) 3.2 пунктның беренче абзацында «хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәләре буларак килеп чыккан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда» сүзләрен «мобилизация чорында, сугыш хәле кертелгән чорда, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3.3 пунктта:

беренче абзацта «матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркынычсыз районнарга» сүзләрен «матди һәм мәдәни байлыкларны саклауга» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацка «халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклау» сүзләрен өстәргә;

г) 3.4 пунктның дүртенче абзацында «сугыш вакытында» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 3.6 пунктта:

беренче абзацта «хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәләре буларак килеп чыккан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында халык өчен куркыныч килеп

туу» сүзләрен «мобилизация чорында, сугыш хәле кертелгән чорда, сугыш вакытында килеп туган куркынычлар» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «оборонасы һәм» сүзләрен «оборонасы, тиешле көчләрне коралландыру һәм әзерләү» сүзләренә алмаштырырга;

е) 3.7 пунктта:

беренче абзацта «хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәләре буларак килеп чыккан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «мобилизация чорында, сугыш хәле кертелгән чорда, сугыш вакытында килеп туган куркынычлар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзацта «хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәләре буларак» сүзләрен «мобилизация чорында, сугыш хәле кертелгән чорда, сугыш вакытында килеп туган куркынычлар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «халыкны ял йортларында, пансионатларда һәм башка савыктыру учреждениеләрендә, вакытлыча торакларда (җыелмалы йортларда, палаткаларда, землянкаларда һ.б.ш.) урнаштыру, шулай ук аларны бушаган торак биналарда урнаштыру» сүзләрен «вакытлыча урнашу һәм туклану пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 3.8 пунктта:

беренче абзацта «хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәләре буларак килеп чыккан» сүзләрен «мобилизация чорында, сугыш хәле кертелгән чорда, сугыш вакытында килеп туган куркынычлар нәтиҗәсендә булган» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «сугыш вакытында» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «, сугыш вакытында» сүзләрен төшереп калдырырга;

з) 3.11 пунктның беренче абзацында «хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәләре буларак килеп чыккан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «мобилизация чорында, сугыш хәле кертелгән чорда, сугыш вакытында килеп туган куркынычлар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

и) 3.14 пунктта:

беренче абзацта «хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәләре буларак килеп чыккан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «мобилизация чорында, сугыш хәле кертелгән чорда, сугыш вакытында килеп туган куркынычлар» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «тыныч чорда һәм сугыш чорында» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «тыныч чорда һәм сугыш чорында» сүзләрен төшереп калдырырга;

к) 4.8 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы территориясендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«граждан оборонасы өлкәсендә бурычларны хәл итәргә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органы;»;

л) 4.13 пунктта:

беренче абзацка «граждан оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итүдә катнашу һәм кешеләр гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янау белән бәйле булмаган гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бетерү буенча кичектергесез эшләрне башкару максатында үз хезмәткәрләреннән булган» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «локаль хәбәр итү системаларын булдыралар һәм даими әзерлек хәлендә тоталар» сүзләрен «халыкка хәбәр итү локаль системаларын булдыралар, яңартып коралар һәм файдалануга даими әзерлек хәлендә тоталар» сүзләренә алмаштырырга;

м) 4.17 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.17. Граждан оборонасы белән идарә итү өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар граждан оборонасы өлкәсендәге үзләренә бирелгән вәкаләтләр нигезендә граждан оборонасына идарә итү техник системаларын, халыкка хәбәр итү системаларын эшлиләр, яңартып коралар һәм файдалануга даими әзерлек хәлендә тоталар.»;

н) 4.19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.19. Федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның граждан оборонасы буенча чараларны гамәлгә ашырганда башкара торган эшчәнлеге «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе тарафыннан координацияләнә.

Граждан оборонасы белән идарә итү, граждан оборонасы көчләре һәм чаралары белән идарә итү органнары эшчәнлеген координацияләүне, граждан оборонасы өлкәсендә бурычларны хәл иткәндә, шулай ук граждан оборонасы өлкәсендә карарлар кабул итүгә мәгълүмати ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашырганда федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның мәгълүмати хезмәттәшлеген оештыруны тәэмин итүне федераль законнар нигезендә Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе кризислы хәлләрдә идарә итү үзәге гамәлгә ашыра.»;

о) 5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Татарстан Республикасы территориясендә граждан оборонасын алып баруга әзерлек халыкны, матди һәм мәдәни байлыкларны мобилизация чорында, сугыш хәле кертелгән чорда, сугыш вакытында килеп туган куркынычлардан саклауга әзерләнү чараларын алдан ук башкарудан гыйбарәт.»;

п) 5.2 пунктта «хәрби низаглар вакытында яисә бу низаглар нәтиҗәләре буларак килеп чыккан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «мобилизация чорында, сугыш хәле кертелгән чорда, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырырга;

р) 5.3 пунктта «һәм сугыш вакытында табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бетерү» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 19 июнь
№ 491